**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_28.04.2021_ ___469-п__

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 6 июнендәге 645-п номерлы боерыгы белән расланган Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен гаризалар карау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы бирүгә гаризалар карау процедурасының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 6 июнендәге 645-п номерлы боерыгы белән расланган Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен гаризалар карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Билгеләнгән тәртиптә Исемлеккә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану төре закон нигезендә Министрлык тарафыннан җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларының һәр конкрет кишәрлегенә карата билгеләнә.»

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү максатларында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы алу өчен гариза расланган Исемлекне Министрлык сайтында беренче тапкыр яисә элегрәк расланган Исемлеккә өстәмәләр бастырып чыгарылганнан соң бирелә.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алу өчен расланган Исемлек сайтта беренче тапкыр яисә элегрәк расланган Исемлеккә өстәмәләр басылып чыкканнан соң утыз эш көне эчендә таләпләргә туры килә торган ике яки аннан күбрәк гариза теркәлгән булса, Министрлык мондый җир асты байлыклары кишәрлегенә карата файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм алу максатларында җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына билгеләнгән тәртиптә аукцион уздырылуын оештыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән срокны бозып бирелгән гаризалар карауга кабул ителми.

Министрлык Исемлеккә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән алга таба файдалану хокукын бирү максатларында, җир асты байлыкларыннан файдалану төрен «геологик өйрәнү» төреннән «геологик өйрәнү, разведкалау һәм алу» төренә үзгәртергә хокуклы, түбәндәге очракларда:

- әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок узып киткәч алынган гаризалар булмаганда;

- геологик разведка эшләре комплексы фактта уздырылмаган очракта, гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында, геологик өйрәнү өчен бирелгән җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган очракта.».

2. Хокукый тәэминат бүлеге җитәкчесенә (А.И.Ткачукка) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гойбәдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков